**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге составына керүче Федоровка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**2020 елның 03 декабрь** **№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге Советының составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2019 елның 05 ноябрендәге 102 номерлы Татарстан Республикасы Аксубай авыл җирлеге Советы карары белән, Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлегенең Федоровка авылында 2021 елның 03 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?"

**1.Беловка авыл җирлеге Федоровка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

--Федоровка торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: грунт күтәрү, грейдлау, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Федоровка торак пункты чикләрендә юлларны кыш көне карап тоту (юлларны кардан чистарту, запас частьләр, җайланмалар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**2. КККНЫ җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу).

« РИЗА» « КАРШЫ» “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә. Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 34 граждан кертелген, җыенда катнашкан гражданнар саны 19 граждан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

" РИЗА " позициясе өчен халык җыенында катнашучы 19 кеше тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.
"тыелып калды" позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып,халык җыены карар итте:
1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге составына керуче Федоровка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?

**1.Беловка авыл җирлеге Федоровка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
--Федоровка торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: грунт күтәрү, грейдлау, вак таш салу, тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Федоровка торак пункты чикләрендә юлларны кыш көне карап тоту (юлларны кардан чистарту, запас частьләр, җайланмалар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).
**2. КККНЫ җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу). .

3.Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Аксубай
муниципаль районының Беловка
авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов